ГЛАВА КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

“8 ” ноябрь 2019 ел. №5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча граждаңнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Еники Чишмә авылы, Совет урамы , 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Еники Чишмә авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 23 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Еники Чишмә авылы торак пуктында Совет урамына юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);

-Еники Чишмә авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Еники Чишмә авылы торак пунктында елга янында янгын техникасы белән су алу өчен пирс булдыру ( сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча түләү);
- Еники Чишмә торак пунктында энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитетына Еники Чишмә авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габидуллин